ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.11.2019 Казан шәһәре № 5-13/тэ

Кулланучыларга «Индустриаль парк-Сервис» идарәче компаниясе җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан бирелә торган җылылык саклау матдәсенә 2020 елга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 23.11.2018 № 5-46/тэ карары белән билгеләнгән озак сроклы тарифларга үзгәрешләр кертү турында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя кую турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә һәм 2018-2021 елларга җайга салынучы оешманың план буенча кирәкле тулай табышын тәгаенләштереп, 2020-2021 елларга җылылык саклый торган матдәгә озак сроклы тарифларга төзәтмәләр кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2019-2021 елларга «Индустриаль парк-Сервис» идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга җиткерелә торган җылылык саклау матдәсенә тарифлар билгеләү турында» 23.11.2018 № 5-46/тэ карарына 1 кушымтага, аны яңа редакциядә бәян итеп (кушымтада бирелә), үзгәрешләр кертергә.

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 23.11.2018 № 5-46/тэ карарына 1 нче кушымта (Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитетының 13.11.2019 № 5-13/тэ карары редакциясендә)

«Индустриаль парк - Сервис» идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга җиткерелә торган җылылык саклау матдәсенә 2019-2021 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлекнең, җайга салынучы оешманың аталышы | Тариф төре | Ел | Җылылык энергиясен тапшыру матдәсенең төре | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | су | пар |
| | Кулланучыларга җиткерелә торган җылысаклагычка тариф | | | | |
| | Түбән Кама муниципаль районы | | | | |
| 1 | «Индустриаль парк-Сервис» идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | Бер ставкалы, сум/куб.м | 01.01.2019 башлап 30.06.2019 кадәр | 141,00 | - |
| | | | 01.07.2019 башлап 31.12.2019 кадәр | 144,12 | - |
| | | | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 139,80 | - |
| | | | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 143,92 | - |
| | | | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 143,92 | - |
| | | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 148,73 | - |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге